САКЛАНГАННЫ САКЛАР

Кошчылык һәм терлекчелектә авыруларны ничек булдырмый калырга?

> 2



МАРАТ КӘБИРОВ:

«Аңа кадәр үземне ничава гына яшим дип уйлый идем»

> 7

БИШ БАЛАЛЫ ХӘНИФОВЛАР:

«Бәхет – үз кулларында»

> 7

БӘРӘКӘТ

«ВТ»ның Татарстанда яшәүче милләтләр турында махсус проекты

> 8

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 141 (29108) | Чәршәмбе | 27 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ИҢ КӨТЕЛГӘН ТУГАН КӨН

Мәүлид бәйрәме – 2023

Безнең белән сөйләшкәндә, Казаннан Энҗе Хисамиева: «Ахшамга кадәр йортҗирне җыештырып, тәмле табыннар корырга өлгерәсе иде», – дип ашкынды. Сәбәбе дә нинди бит: Мәүлид кичәсе җиткән! Мөселманнар аны 26 сентябрьдән 27сенә каршы кичтә билгеләп үтте. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) өммәтеннән булуын раслап, бу көнгә бәйле барлык таләпләрне мөмкин булганча үтәргә тырышкан әңгәмәдәшебез дә.

– Уразага кердем. Әни белән сөйләшеп куйган идек, ул да керде, – ди Энҗе. – Бу – чынлап та, без – мөселманнар өчен зур бәйрәм. Бу көнне тәмле ризыклар әзерләп, шартын китереп уздыру, бик күп салаватлар әйтү мөһим. Без – пәйгамбәребез (с.г.в.) өммәтеннән. Безнең догаларны, уразаларны Аллаһы Тәгалә кабул кылсын иде әле!

Савaплы булырга бер сәбәп

Мәгълүм булганча, 2023 елның 15 сентябрендә мөселман календаре буенча иң күркәм айларның берсенә – мөбарәк мәүлид ән-нәби аена кердек. Бу айның әһәмияте шунда: бу айда Аллаһының соңгы илчесе, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган. «Мәүлид» сүзе дә гарәпчәдән «туу» дигәнне аңлата. Мәүлид ае 15 октябрьдә тәгәлләнә.

Бу көнне матур итеп үткәрергә кирәк. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «шимбә киңәшмәсе»ндә әнә шундый бурыч куйды. Республика җитәкчесе әлеге көннең әһәмиятле һәм олуг бәйрәм саналуын искәртте.

Мөселманнарның «Бу көнне ничек үткәрергә?» дигән соравына «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин җавап бирде.

– Күбрәк салаватлар әйтергә, изгелек кылырга, сәдака бирергә, пәйгамбәребезнең (с.г.в.) күркәм сыйфатлары, тормышы турында башкаларга сөйләргә кирәк, – ди ул. – Бу – бик әһәмиятле көн. Пәйгамбәребез Мөхәммәдтән (с.г.в.) соң башка пәйгамбәр булмас. Мөмкинлеккә карап, бу көнне һәр мөселманның тиешенчә үткәрүе хәерле. Мәүлид кичендә дә таба исе чыгарырга, тәмле табыннар корырга мөмкин.

Балык Бистәсе районы Тәберде Чаллысы авылы мәчете мөгаллиме Раил хәзрәт Фәйзрахманов әйтүенчә, мәүлид ае уңаеннан мәчетләрдә төрле чаралар ниятләнгән.

– Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) кыскача тормыш юлын сөйләү, әдәбе, әхлагы, холкы, нинди булуы турында мәгълүмат бирелә, дәресләр уза, вәгазьләр сөйләнелә. Балалар катнашында «Пәйгамбәреңне беләсеңме?» дигән викторина уза. Аларга «Ул нәрсәгә өндәгән?», «Кайда туган?», «Ничә баласы булган?» кебек сораулар бирелә, – диде дин әһеле.

Башкаланың Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан мәдрәсәсендә көндезге бүлектә укучы шәкертләр өчен Мәүлид кичәсе узган. Уку йорты җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин сүзләренчә, мәдрәсәдә мәүлид ае дәвамында төрле чаралар үткәрелә. Көн саен өйлә намазыннан соң пәйгамбәребезгә (с.г.в.) багышланган вәгазьләр сөйләнә. Ачык дәрес узган, Мәүлид касыйдәсен башкарганнар.

Болгарда көтәләр

Изге Болгар җирендә мәүлид аена бәйле чаралар 24 сентябрьдән үк башланып 1 октябрьгә кадәр дәвам итә. Академиядән хәбәр итүләренчә, бу көннәрдә Россиянең төрле төбәкләреннән килгән рәссамнар белән «Болгар ривайәтләре» симпозиумы узачак. Әлеге симпозиумның нәтиҗәсе буларак күргәзмә оештырылачак. Аны Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә карар дип көтелә.

spas-rt.ru

Болгар ислам академиясе – Россия Президенты Владимир Путин тарафыннан хупланган федераль проект. 2018 елда Болгарга эш сәфәре белән килгәч, ил башлыгы: «Болгар ислам академиясе барлыкка килгәч, безнең бөтен өчлек – мәдрәсә, югары уку йорты, академия формалашты. Безнең ил өчен мөһим һәм бик кирәкле проект бу. Традицион ислам – илебез мәдәни кодының аерылгысыз, ә мөселман өммәте – Россиянең күпмилләтле халкының мөһим өлеше», – дигән иде.

САН

Дөньяда барлыгы **1,6 млрд** кеше ислам динен тота. Мөселманнар нигездә Төньяк Африкада, Якын Көнчыгышта, Үзәк һәм Көньяк Азиядә, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә, Балканда, Кавказда яши.
Россиядә **146 млн** кеше яши, ислам динендә булучылар бар халыкның **10** процентын тәшкил итә.
Республикада **2112** дини корылма бар. Шуларның **90** проценты – ислам һәм православие гыйбадәтханәләре.

Төзекләндергәннәр

Татарстанда 3 федераль һәм республика программасы кысасында 118 фельдшер-акушерлык пункты төзекләндерелгән. Шуның 117се – «Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының «Сәламәтлек саклау өлкәсенең беренчел буынын модернизацияләү» федераль программасы буенча. Барлыгы 30 районның медицина пунктлары яңартылган.

Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин әйтүенчә, социаль-мәдәни өлкә объектларын, куфатирлы йортларны төзекләндерү программалары да тәгәлләнеп килә.

15 оешма бинасында ремонт дәвам итә. Аларда төзекләндерү эшләре 83 процента үтәлгән. Бу атнада Яшел Үзән районында ремонт эшләре тәгәлләнгән.

Нигә саега?

Елгаларның саегуы законсыз төзелешкә, җирнең чүпләнүенә китерергә мөмкин. Роспотребнадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе Фаяз Шакиров мондый сулыклар тирәсендә төзелеш алып бармаска чакырган. «Бүген яр буенда суның юкка чыгуы ярның эчкәрәк күчүен аңлатмый. Безнең яр буе сызыкларын билгеләнгән. Шуңа күрә хәтта су киткән урыннарда да нәрсәләрдер төзү тыела», – дип билгеләп үткән ул. Шул ук вакытта, аның әйтүенчә, Казансуның саегуы моңа кадәр су астында булган чүпнең өскә чыгуына, ягъни җирнең чүпләнүенә китергән.

Соңгы атналарда Куйбышев сусаклагычында, аерым алганда, Казансу елгасында су хәйран кимеде. Сентябрь башында аның тирәнлеге нибары 50,46 метрга калган. Мондый хәлнең элегрәк тә булганы бар иде.

Чирләмәскә иде

Татарстанда коронавирус йоктыручылар саны арта. 18–24 сентябрь чорында чир иярткән 109 очрагы теркәлгән. Алдагы атнадагыга караганда 1,4 тапкыр зуррак сан бу.

COVID-19 таралуга каршы көрәш буенча федераль оператив штаб мәгълүматларына караганда, Татарстанда инде берничә атна рәттән чирләүчеләр сафы ишәя. 4–10 сентябрьдә республикада вирус йоктыруның 63 очрагы ачыкланса, 11–17 сентябрьдә – 77 очрак.

Бер атна эчендә Татарстанда 81 сырхау хастаханәгә озатылган. 51 кеше савыккан. Шөкер, республикада яңа үлем-китем очраклары юк. Пандемия башланганнан бирле бездә барлыгы 207118 кеше чирләгән, 2010 кеше вафат булган.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ковид, шулай ук ОРВИ һәм грипп белән авыручылар саны артуга игътибар итте. Ул республикада яшәүчеләрне чирне кисәтү чараларын үтәргә өндәде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңалык

Мин сине һаман көтәм, көтәм...

ЯТИМНӘРГӘ ФАТИР БИРҮНЕ СЕРТИФИКАТ БЕЛӘН ТИЗЛӘТМӘКЧЕЛӘР

Хәзерге вакытта 275 меңнән артык ятим бала дәүләт вәгъдә иткән фатирын көтә. Ел саен аларның якынча 10 процентына торак бирелсә, чиратка басучылар саны да шуның кадәр арта. Әлеге мәсьәләне ничек тә булса җайга салу өчен, Россия Хөкүмәте йортында ятимнәргә махсус сертификатлар өләшә башларга тәкъдим иттеләр.

275333. Агымдагы елның февраль аена торак алыр өчен чиратка басучылар саны әнә шуның кадәр булган. Бу санны Дәүләт Думасының Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар мәсьәләләре комитеты җитәкчесе Нина Останина китерде. Белгечләр исәпләвенчә, бу балаларга торак бирү эшен тәмам итәргә 14 елдан алып 40 елга кадәр вакыт кирәк булырга мөмкин.

Фикер

20 ятимне тәрбиягә алып үстерүче ханым (исемен күрсәтмәвебезне үтенде) белән элемтәгә кереп, әлеге яңалыкка карата фикерен белештек. «Бик әйбәт булыр иде. Дәресен генә әйткәндә, безнең моңарчы фатир алу белән проблемалар булмады. Өч балабыз фатирлы, тагын берсе армиядә, кайту белән, шушы мәсьәләне кутәрергә ниятлибез. Фатир алу өчен документларны балага 14 яшь тулуга тапшырабыз. Чиратка бастыралармы, юкмы – көтәбез. Бер улыбызга студент чагында ук бирделәр. Стипендиясе яхшы иде, пенсия дә алды. Кереме яхшы, ТКХ өчен түләрлек мөмкинлеге бар иде», – дип сөйләде ул.

Проблеманың сәбәбе – торак төзелешенең акрын баруы. Аерым алганда, күп кенә төбәкләр бу мәсьәлә белән бөтенләй диярлек шөгыльләнми. Шуңа да чиратлар кимеми, арта гына.

Моны хәл итәр өчен, Министрлар Кабинетында махсус сертификатлар булдырырга тәкъдим иттеләр. Алар исәбенә ятимнәр үзләре торак сатып ала, ипотекаларын түли. Дәүләт Думасының Хезмәт, социаль сәясәт һәм ветераннар эшләре комитеты әгъзасы Светлана Бессараб сүзләре белән әйтсәк, торак сертификаты ярдәмендә яшьләр фатирны үзләре сайлау хокукына ия булачак, бу исә торак проблемаларын тизрәк хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Сертификат кемгә тиеш? Аны алу өчен төп шарт – 23 яшьне тутыру. Ләкин Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володин төбәкләргә яшь буенча үз шартларын кую мөмкинлеген бирергә кушты. «Мондый сертификатны бирү яшен 21гә кадәр киметү төбәкләргә әлеге мәсьәләне күпкә тизрәк хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк», – диде ул.

Моннан тыш, торак сертификаты беренче чиратта махсус хәрби операциядә катнашучыларга, шулай ук балаcы булган яшь ана капиталын торак алу өчен тотарга җыенучыларга бирелачәк.

Закон нигезендә, сертификат акчаларын төбәк хакимияте турыдан-туры фатир сатучыларның исәп-хисап счетларына җибәрә. Әгәр сертификат ияләре аны ипотека кредитын түләү өчен файдаланырга теләсә, акча килешү төзелгән кредит оешмасы хисабына күчерелә.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сүзгә-сүз

Яна ЛАНТРАТОВА, Дәүләт Думасы Мәгариф комитеты рәисенең беренче урынбасары:

Кибетләрдә ризыкларны бушлай тарату пенсионерлар өчен генә түгел, аз керемләр өчен дә зур ярдәм булачак. Мондый тәҗрибә кайбер илләрдә уңышлы кулланыла. Социаль киштәләрне булдыруга эшмәкәрләрне җәлеп итәргә кирәк. Бәлки, аларны салымны киметеп җәлеп итеп булыр.

(«Аргументы и факты» газетасыннан)

РОССИЯДӘ – ХЕЗМӘТ ХАКЫ

«РИА Новости» агентлыгы Россия шәһәрләрендәге хезмәт хакы күләмен тикшергән. Тикшерү өчен 2023 елның I квартал мәгълүматларын алганнар.

Урын	Шәһәр	Хезмәт хакы (мең сум)
1	Яңа Уренгой	142,6
2	Салехард	127,2
...		
9	Санкт-Петербург	93,7
...		
19	Екатеринбург	69,6
...		
22	**Казан**	**63,2**
...		
29	Уфа	60,6

Иске яңаны... сакламый

24 октябрьдән үк кушымтасы иске смартфоннарда эшләми башлаячак. Мессенджер сайтында хәбәр ителгәнчә, кушымта 5.0 һәм аннан яңарак Андроидлы смартфоннарда гына кала. Иске программалы гаджетларның кушымтаны эшләтү өчен билгеләнгән таләпләргә, иминлек таләпләренә җавап бирмәвенә бәйле бу. WhatsApp эшен яңарту өчен Андроидның 5тән ким булмаган смартфон юнәтергә кирәк булачак.

Шулай итеп, октябрь ахырында иске смартфоннардан WhatsApp аша шалтырату һәм хәбәрләр җибәрү мөмкинлеге юкка чыга.

Моңа кадәр WhatsApp мессенджерының 150дән артыграк илдә каналлар булдырачагы турында хәбәр ителде. Россиядә исә аның каналлары барлыкка килмәячәк.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ТАЦИТ ТОЗАГЫНА ТӨШКӘНДӘ

Дөнья икътисадында вакыйгалар зур кризисны искә алырлык дәрәҗәдә кискенләште. Кытайда төзелеш тармагының җимерелүе, мөгаен, ул кризисның бөек стартын башлап җибәрер. Без икътисад турындагы язмаларыбызда искәртеп килдек: төзелешкә артык күп инвестицияләр кертү печәнне арбаның бер ягына өюгә тиң. Биегрәк өйгән саен арба чайкала һәм ава. Глобаль икътисадта без шул мизгелнең якынаюын күзәтәбез. Кытайда сатылмаган торакның гомуми мәйданы 648 миллион квадрат метрга җиткән. Бу – 90 квадрат метрлы 7,2 миллион фатир дигән сүз. Тагын да радикальрәк бәя дә бар. Кытай Дәүләт статистикасы башлыгының элекке урынбасары Хэ Кэн 3 миллиард кешегә җитәрлек буш торучы йортлар (төзелеп бетмәгәннәрен дә кертеп) барлыгын әйтә. Ике Кытай халкын кертеп тутырганнан соң да байтак буш фатирлар калачак әле. Вазгыятьне халыкка бушлай акча өләшеп кенә коткарып була. Әмма ул есул да озак булышмаячак.

Германиядә дә төзелеш секторы кризиска кереп килә. Бөтен ил буйлап төзелеш туктала, төзелеш мәйданнарындагы техника юкка чыга. Соңгы елларда тармак түбән процент ставкалары, масштаблы инвестицияләр нәтиҗәсендә кызу темплар белән үскән иде. Европа Үзәк банкы, инфляция белән көрәшәм дип, төп ставканы күтәргәннән соң, ипотека кыйммәтләнде, торак бәяләре төшә башлады. Төзелеш компанияләре банкротлыкка чыга. Вак компанияләр дә, эреләре дә кыен хәлдә. Vonovia дип аталган төзелеш гиганты 60 мең фатирда эшне туктаткан. Август аенда һәр бишенче компания вакытлыча эштән туктаган. Мондый хәлнең соңгы утыз елда күренгәне юк иде, диләр.

2008 елгы кризис АКШта төзелеш тармагын гадәттән тыш финанслау нәтиҗәсендә башланган һәм бөтен дөньяга финанс кризисы булып җәелгән иде. Америка икътисады бүген үзен чагыштырмача яхшы күрсәтә. Анда хәл Кытайдагыдан да, Европадагыдан да уңайрак. Хәтта Трамп идарә иткән еллар белән чагыштырганда да күрсәткечләр әйбәт. Ләкин шуңа карамастан, гамәлдәге Президент Байденның рейтингы төшә. Бер елдан соң анда Президент сайларга тиешләр. Сайлау алды көрәше башланды инде. Соңгы сораштырулар Байденның – 42, Трампның 52 процент тавыш җыюын күрсәтә. Байден Тацит тозагына төште, ди белгечләр. Рим тарихчысы Тацит император Гальбаның популярлыгы югалу турында шулай язып калдырган. Император яхшы адым ясаса да, начарын атласа да, рейтингы төшкән. Байден да шул тозакка капты, диләр. Бер елдан соң зур борылыш башлану ихтималын белдерә бу, әмма кая гына борылмасын, Америка да кризис кочагына барып керәчәк.

Россиядә

ЭКСПОРТНЫ ПОШЛИНА БЕЛӘН КИМЕТҮ

Россиядә дә төзелеш тармагы гадәттән тыш темплар белән финанслана. Эчке тулай продуктның үсешен тәэмин итә бу. Бездә дә сатылмаган торак күләме 75 процентка җитә, дигән саннар күренеп алды беравык. Әмма торакка бәяләрнең ашкын үсеше халыкның аны инвестиция инструменты буларак файдалануына этәрә. Кешеләр әле бездә ипотеканы рекордлы темплар белән ала һәм торак базарында хәл Кытайдагыдан да, Көнбатыштагыдан да аерылып тора. Күз күреме кадәр ераклыкта гына кризис шәйләнми. Федераль хөкүмәтнең төп проблемасы – девальвация һәм инфляция. Кайбер белгечләр фикеренчә, доллар бу атнаның пәнҗешәмбесендә янә сикерер. Моңа алшартлар, чынлап та, бар. Нефть бәясе күтәрелүгә карамастан, экспорт кереме импорттан өстен чыга алмый. Моның ике сәбәбе бар, диләр. Берсе – «кара алтын» конвертацияләнми торган валюталарга сатыла. Аларны долларга әйләндерү кыен. Икенчесе – экспортчылар валюта керемен чит ил банкларындагы хисапларда яшерә. Илгә кайтармый. Путин указ белән моны рөхсәт итте.

Федераль хөкүмәт валюта курсы өчен артык борчылмый шикелле. Доллар курсының югары торуы бюджетны сумнар белән коендыра. Процент ставкасын күтәрү девальвациядән саклар дип тә уйлыйлар кебек Мәскәүдә... Һәм министрлар кызыклы ат йөреше ясарга җыена. Машина төзелеше продукциясеннән тыш экспортка китә торган барлык товарларга экспорт пошлинасы кертергә ниятлиләр. Пошлинаның күләме доллар курсына бәйле булачак. Доллар 80–85 сум торганда, экспорт салымы 4 процент булачак. 85–90 сумлык долларда – 4,5; 90–95 сумлыгы – 5,5; 95 сумнан кыйммәтрәк булса, 7 процентлы пошлина тәэмин итәчәк. Бу чара быел ук гамәлгә кереп, 2024 ел ахырына кадәр кулланылачак дип уйланыла. Беренче карашка хөкүмәтнең ниятендә рациональ орлык бар кебек. Доллар үскән саен, экспортчылар күбрәк табыш ала. Шул табышны казнага каерып алсаң, бюджет та тула, товарны эчке базарда сату отышлы була башлый һәм, ихтимал, инфляция дә кими.

Күпчелек белгечләр моны үз-үзеңне үтерүгә тиң адым дип бәяли. Экспортка киткән товарлар тышкы базарда көндәшлеккә чыдамас, сәүдә кимер, дип фаразлыйлар. Валюта кереме кимү доллар курсын тагын да өскәрәк чөяр, курс күтәрелгәч, күбрәк пошлина түләргә туры килер дип уйларга нигез бар. Хөкүмәт яхшылык теләп, белгеле, әмма Россиядә Черномырдин формуласы эшли мондый чакта: «яхшы булсын дип уйлыйсың, һәрвакыттагыча килеп чыга».

ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

Гуманитар ярдәм

Казаннан Луганск Халык Республикасының Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре тарафына гуманитар йөк төягән тагын 10 машина юлга кузгалды. Бу юлы «Бердәм Россия» партиясенең төбәк бүлеге ярдәмендә җыелган йөкнең гомуми авырлыгы бик зур – 200 тонна чамасы. Аны «Бәхетле» складыннан төяп озаттылар.

Дәүләт Советы Рәисе – «Бердәм Россия»нең Татарстандагы төбәк бүлеге Секретаре Фәрит Мөхәммәтшин хәйрия акциясендә катнашучылар һәм волонтерлар белән очрашты. «Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә инде менә 16 нчы тапкыр гуманитар йөк озатабыз, – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Башта без Татарстан шефлыгындагы шәһәрләрдә яшәүчеләрдән нәрсәләргә ихтыяҗ кичерүләрен белешәбез. Аларның үтенече белән бүгенгә иң кирәкле әйберләр – азык-төлек, киемсалым, аяк киеме, дәреслекләр, электр приборлары, башка әйберләр алып барабыз». Парламент башлыгы, мондый гуманитар акцияләрдә катнашкан өчен, гади кешеләргә, депутатлар, муниципаль районнарның партия оешмалары җитәкчеләренә рәхмәт сүзләре ирештерде.

Фәрит Мөхәммәтшин билгеләп үткәнчә, «Бердәм Россия»нең гуманитар акцияләренә партиянең «Яшь гвардия»челәре дә инде күптән кушылган. Бу юлы да алар Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләренә бара. «Яшь гвардия»челәр анда Донецк һәм Луганск халык республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләренең Россиягә кушылу көне хөрмәтенә ватанпәрвәрлек акцияләре үткәрәчәк.

Бу юлы Донбасска, башка әйберләр белән берләштән, 100 тоннадан артык яшелчә дә төяп озатылган. Дәүләт Советы депутаты, «Татагролизинг» генераль директоры Азат Җиһаншин ярдәмнең шушы өлешен җыюга зур өлеш керткән. «Инде унынчы тапкыр гуманитар йөк җыюда катнашабыз. Авыл хуҗалыгы тармагында эшләүче коллегаларым иң кирәкле хәрби-учет белгечләренә ия булып чыкты. Безнең бурыч – бүген намус белән хезмәт итүче, алгы сызыкта үз бурычын үтәүче егетләргә булышу. Шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре белән дә даими элемтәдә торабыз, аларга төрлечә ярдәм итәбез», – дип билгеләп үтте депутат.

Лисичанск шәһәренә мәктәп китапханәләре өчен «Бердәм Россия»нең «Яшь гвардия»челәре катнашында җыелган 5 мең китап, җиһазлар да озатылды.

Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләрендә яшәүчеләрнең үтенече буенча чиста су, төзелеш кораллары һәм материаллар да юлланды. Ярдәм җыюда Түбән Кама, Сарман, Яңа Чишмә, Минзәлә, Балтач, Мамадыш, Югары Ослан, Апас, Алабуга, Кайбыч районнары, шулай ук Казанның Киров һәм Идел буе районнары катнашкан. Дәүләт Думасы депутатлары Марат Нуриев, Руслан Гаджиев, республика предприятиеләре һәм оешмалары да үзләреннән саллы өлеш керткән.

Бердәмроссиялеләр ярдәмендә җыелган гуманитар йөкне партиянең төбәк бүлеге башкарма комитеты җитәкчесе Марат Сәмигуллин һәм «Яшь гвардия»челәр илтеп бирәчәк.

Исегезгә төшерәбез: махсус хәрби операция башланганнан бирле Татарстаннан Луганск Халык Республикасына 1750 тоннадан артыграк йөк (115 машина) гуманитар ярдәм юлланган.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

tatarstan.ru

ДӘРӘҖӘЛЕ БҮЛӘК СЕБЕРГӘ КИТӘ

Фәнни дөнья

Инде хәбәр ителгәнчә, бу көннәрдә Казанда Фән атнасы узды-рыла. Аның кысасында Татарстан Фәннәр академиясендә күренекле физик Евгений Завойский исемендәге Халыкара премия тапшыру тантанасы үткәрелде.

Премия, 1991 елдан башлап, һәр ел саен бирелә. Аның белән Казан университетында ачылган күренеш – электрон парамагнит резонансны куллану яки үстерүгә зур өлеш кертүчеләр бүләкләнә.

Быел халыкара премияне Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Фәрит Мөхәммәтшин тапшырды. Ул галимнәрне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Советы һәм Хөкүмәт исеменнән сәламләп, әлеге тарихи вакыйганың мөһимлеген билгеләп үтте. «Завойский исемендәге премия, Казанның башка дәрәҗәле премияләре белән берләштән, дөнья фәнен алга таба үстерүгә, галимнәргә яңа ачышлар ясауга этәргеч бирергә тиеш, – дип басым ясап әйтте Фәрит Мөхәммәтшин. – Күренекле галимнәребезнең, Казанның танылган фәнни мәктәпләре вәкилләре исемнәрен – ә алар исәбенә, һичшиксез, физик-экспериментатор, Социалистик Хезмәт Герое Евгений Завойский да керә – мәңгеләштерүне мөһим максат дип саныйм».

Парламент башлыгы Россия Фәннәр академиясе академигы, Казан физик-техник институты фәнни җитәкчесе Кев Салиховка (әлеге халыкара бүләк аның тәкъдиме белән гамәлгә куелган) рәхмәт сүзләре җиткерде. «Татарстан өчен – күп юнәлешле икътисадка һәм нык үсеше сәнәгатькә, авыл хуҗалыгына ия булган республика өчен – фәнне үстерү һәм югары квалификацияле кадрлар әзерләү һәрвакыт бик зур әһәмияткә ия булды», – дип билгеләп үтте Фәрит Мөхәммәтшин.

Быел Завойский исемендәге премияне бирү буенча халыкара комитет карары нигезендә, профессор, Россия Фәннәр академиясенең Себер бүлеге Новосибирск органик химия институты директоры Елена Багрянская электромагнит резонанс өлкәсендә дәрәҗәле бүләккә лаек булды. Фәрит Мөхәммәтшин аңа диплом һәм лауреат медале тапшырды. «Елена Багрянскаяның тикшеренүләре бер генә түгел, ә күп тармаклар: икътисад, медицина, сәнәгать, авыл хуҗалыгы тармаклары өчен бик мөһим», – диде Дәүләт Советы Рәисе.

Елена Багрянскаяның дәрәҗәле бүләге белән шулай ук Татарстан Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов, КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Дмитрий Таюрский котлады.

Борчыган мәсьәлә

САКЛАНУ ҖИТМИ

Терлекләр, кошлар арасында кайчандыр булып онытылган авырулар баш калкыта башлаган. Аларга яңалары, моңа кадәр очрамаганнары да өстәлә. Хәвеф төрле яктан сагаласа да, әлегә кадәр күпчелек оешмалар биологик куркынычсызлыкны кайгыртмаган. Бу – ул-бу була калса, бизнес бер көндә юкка чыгарга мөмкин дигән сүз.

Идар Мөхәммәтҗанов

Билгеле булганча, август ахырында Лениногорск районындагы кош фабрикасында кош гриппы чыгып, 213 мең баш кош һәм 225 мең йомырка юк ителде. Шулай ук якын-тирә авылларда яшәүче халыкның 177 баш тавыгы алынды.

– Әлеге вакытта бина чиста, якын көннәрдә бу учакны ябачакбыз. Фабрикага – 50 млн сум, халыкка 60 мең сумлык зыян килде. Кешеләргә компенсация түләнәчәк, – диде журналистлар белән очрашуда Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы Алмаз Хисаметдинов.

Ә менә фабрика акча алырмы, юкмы – анысы әлегә билгеле түгел. Россельхознадзор федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Илнур Галиев аңлатканча, гаеп фабриканың үзендә булса, компенсация тәтемәячәк.

– Безнең өчен авыру чыгагын табу мөһим, ләкин бу очракта фикерләр каршылыклы бар. Кемдер, кошлар белән керергә мөмкин, ди. Шулай ук Башкортстаннан транспорт, ашлык белән керү ихтималы да тулысынча инкарь итеп булмый. Шуңа күрә әлегә авыру чыганагы буенча сорау ачык кала. Ләкин оешмада берничә төрле җитешсезлек бар иде. Компенсация түләү-түләмәү дә шуннан чыгып хәл ителәчәк, – диде ул.

Сентябрь башында республикада тагын бер күңелсез очрак теркәлде: Яңа Чишмә районында фермер Николай Сковов хуҗалыгындагы мөгезле эре терлекләрдә бруцеллез авыруы ачыкланды.

– Бүгенгә барлык 770 терлек тә юк ителде, бина чистартыла, дезинфекцияләнә. Фермерга турыдан-туры килгән зыян күләме 60 млн сумны тәшкил итә. Ул бернинди дә компенсация ала алмаячак, чөнки бруцеллез иң куркыныч авырулар исемлегенә керми, – диде Алмаз Хисаметдинов.

Аның сүзләренчә, мондый хәл килеп чыгуга фермер үзе гаепле.

– Терлекләрне ярамаган төбәктән кертәннәр, башка чыганак була алмый. Күрше төбәкләр бу авыру буенча имин түгел. Монда терлекләрне ветеринария документларыннан башка гына алып кайтканнар. Бу хәл белән хокук саклау органнары шөгыльләнә, тикшеру бара, – диде республиканың баш ветеринары.

Авыру маллар исә Дагыстандагы махсус ит комбинатына озатылган, ә сәламәт терлекләр Сарман районының Җәлил бистәсендәге комбинатта эшкәртелгән.

Алмаз Хисаметдинов Татарстанда биологик куркынычсызлык белән җитди проблемалар булуын да әйтте. Аның сүзләренчә, 34 кош фабрикасының нибары өчесе генә биологик яктан якланган – терлекләрне йогышлы һәм инвазион авырулардан саклау системасы бар. 17 дуңгызчылык комплексының 12се генә таләпләргә тулысынча җавап бирә. Шулай ук мөгезле эре терлек асрала торган 239 эре предприятие дә биологик яктан сакланмаган.

– Мин турыдан-туры моның өчен җаваплы хуҗалык җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәм. Алга таба да эшләргә теләсәгез, биологик куркынычсызлык белән шөгыльләнергә тиешсез, – диде Алмаз Хисаметдинов. – Элек булып, соңгы елларда онытылган авырулар да, яңалары да баш калкыта башлады. Алар бик тиз тарала. Бу турыда онытмасак иде.

Моннан тыш, идарә башлыгы әйтүенчә, башка төбәкләрдән республикага иң куркыныч авырулар тере терлек белән керә. Арадашчылар терлекчелекне дә, кешеләрне дә куркыныч астына куя, диде ул. Илнур Галиев та үз чыгышында биологик куркынычсызлыкның күп чыгым соравын ясшермәде.

– Әгәр син авыл хуҗалыгы тармагы белән шөгыльләнергә алынасың икән, чыгымнарның күп өлеше биологик куркынычсызлыкны тәэмин итүгә китәсен алдан ук белеп торырга тиеш. Шуңа күрә бизнесны иң элек шуннан башларга кирәк. Башкача булса, бер көндә барысы да юкка чыгарга мөмкин, – диде ул.

Илнур Галиев әйтүенчә, кош һәм терлек оешмаларында хилафлыклар шактый күп очрый. Иң еш кабатлана торганнары – дезбарьерның булмавы яки булып та, аның файдаланылмавы. Моннан тыш, ферманы әйләндереп алган рәшәткә булмау, территориядә агачлар һәм биек үләннәр үсеп утыру да йогышлы авыру үтеп керүгә сәбәп була ала.

– Территориядәге агачларга, биек үскән үлән арасына төрле кошлар оялый. Алар авыру чыганагы булырга мөмкин. Әйтик, язын Россиянең төрле төбәкләрендә акчарлакларда кош гриппы булуы ачыкланган иде. Шуннан соң без барысын да контрольгә алып, тикшереп, әйрәнеп чыктык. Бәхеткә, бер генә акчарлакта да авыру билгеләре табылмады, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Саннар

Бүген Россиядә төрле авырулар буенча вазгыять:

кош гриппы	73
дуңгызларда Африка чумасы	67
бруцеллез	226
сарыкларда һәм кәҗәләрдә чәчәк бизгәге	12
Себер түләмәсе	5
туберкулез	4
котыру авыруы	659 очрак.

ҖЫЛЫ ОЯ

БИШ БАЛАЛЫ ХӘНИФОВЛАР ГАИЛӘСЕ «АТА-АНА ДАНЫ» ОРДЕНЫ МЕДАЛЕНӘ ЛАЕК БУЛДЫ

Людмила Жаренова

Аксубай

Соклану

Бәхет – үз кулыңда! Балалар исә – синең чагылышың. Ничек яшисең, нинди гамәл кыласың, шуны кабатлыйлар. Аксубайда яшәүче Чулпан һәм Иршат Хәнифовлар әнә шулай ди. Бу гаиләне Россия Президенты Владимир Путин указы белән гамәлгә куелган «Ата-ана даны» ордены медале белән бүләкләделәр. Үрнәк гаиләгә медальне Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырачак.

– Бик дулкынланабыз. Мондый дәрәҗәле бүләк алганыбыз юк иде бит әле. Бу – дәрәҗә дә, зур җаваплылык та. Россия Президенты һәм республика җитәкчеләре гаилә традицияләрен саклау өчен зур көч куя. Аларга мең рәхмәт. Үрнәк гаиләләр мисалында яшь буынны тәрбияли алар, – ди Чулпан. – Күңелдә горурлык һәм «дөрес яшибез икән» дигән хисләр бар. Үзебездән бигрәк Аксубаебыз өчен горурланабыз. Шушы җирдә яшәп, гаилә корып, бәхетебезне тапкан кешеләр бит без.

Иршат әфәнде белән сөйләшә алмадык, хатыны әйтмешли, ул көн-төн эштә. Авыл хуҗалыгында эшләгәч, «Аксу-Агро» агрофирмасының башкарма директоры булгач, Чулпан үзе дә, эш вакытында иремне борчымаска тырышам, ди:

– Әтием дә гомер буе җитәкче урыннарда эшләде. Без өч кыз үстек. Яшермим, балачакта әтине күрми дә идек. Ул өйгә йокларга гына кайта иде. Ә без уянганда, эшкә китеп өлгергән була. Әни – сабыр, түзем, ир хакын хаклап яши торган хатын-кыз. Аның сабырлыгы миңа да күчкән. Безнең гаиләдә әтигә хөрмәт зур. Шундый мохиттә үскәч, бездә дә шундый ук сыйфатлар тәрбияләнгән, – ди Чулпан. – Яшерен-батырын түгел, әнинең каенанасы безгә бик яхшы әби булса да, әнигә таләпчәнрәк булды. Әмма әнинең аңа бервакытта да күтәрелеп бәрелгәне, хәтта караңгы чырай күрсәткәне дә булмады. Әни, дип өзелеп торды.

Чулпан белән Иршат Хәнифовларның гаилә коруларына – 22 ел. Алар дүрт ул, бер кыз үстергәннәр. Кияүгә чыкканда, ишле гаилә булырбыз дип уйламаган да Чулпан.

– Күпләр безнең биш бала үстергәнне дә белми икән. Кызымның укытучысы: «Сез – күпбалалы гаиләмени?» – дип сорый. Моңа сөенеп тә куйдым әле. Димәк, читтән караганда арыган, талчыккан булып күренмибез икән (*көлә*). Чынлап торып уйласаң, биш баланың үскәнен сизми дә калдым мин, – ди Чулпан. – Олы улым бик ярдәмчел булды. Динарыма – 21 яшь. Казан дәүләт аграр университетында магистратурада укый. Зәринә кызыма 18 яшь тулды. Ул Россия дәүләт хокук университетына укырга керде. Риналь улым – 8 нче, Сәйдәр улым 4 нче сыйныфта укый. Әйсәребезгә – 4 кенә яшь.

Хәнифовларның бер ятим кызчыкны әти-әниле итәргә дигән хыяллары да бар. Булачак әти-әниләр мәктәбендә укып та чыкканнар. Әлегә өйләрендә ремонт бара. Йортларын матурлап бетергәч, Әйсәр яшендәге бер кызчыкны алып кайтырга дип торалар.

– Мин балаларны бик яратам. Бар назымны бирергә тырышам. Балачаклары исләрендә калырлык булсын дип яшибез. Кайчак әнием, артык күп әйбер аласыз, дип тә куя. Булсын, дим. Алар – безнең дәвамчыларыбыз. Үзебезнең гамәлләр белән аларны тәрбиялибез. Алар бик рәхмәтле булып үсәләр, – ди Чулпан. – Ике әниемне дә бик якын күрәм. Иршатка кияүгә чыккач, үз әнием алдан әйтеп куйды: тагын бер әниле булдың, диде. Каенанам – бик яхшы кеше. «Карап-карап торам да, син бөтен нәрсәне дөрес эшлисең икән», – ди ул миңа. Әниләрнең аяк астында җәннәт икәнне онытмыйк. Ике әниемә дә бертөрле бүләк бирәм, икесен дә тигез итеп кадерлим. Балалар да күреп торсын. Синең ярыңны үстергән анага рәхмәтле булырга кирәк.

Кызганыч, Иршат әфәндене әтисе исән түгел. Иртәрәк киткән. Әнә шуңа да әнисе Фигаль апага ялгызлыкны сиздермәскә тырыша алар. Һәр бәйрәмне әти-әниләре белән бергә үткәрәләр.

– Тормышны бик яратам. Соң ятам, иртә торам. Бар эшкә өлгерәм. Ни генә булса да, ныклы терәгем барлыгын белеп яшим. Ирем белән сүзгә килгәнебез дә юк. Берәр нәрсә ошамаса, утырып сөйләшәбез. Бер-береңә ышаныч кирәк. Ниләр генә сөйләмәсеннәр, мин һәрвакыт үз күзем белән күрсәм генә ышанам. Шуңа да арага ятлар сүзе кертмим. Минем моңа вакытым да юк, – ди ул. – Ирем бик акыллы. Эшендәге бер проблеманы да өйгә алып кайтмый. Кайчак кәефе югын күреп алсам, юатырга тырышам. Тынычландырам, үсендереп торам. Ирләргә дә ныклы тыл кирәк.

Быел Хәнифовларны республика күләмендә бүләкләмәкче булганнар. Ирешкән уңышларын барлап, документ җыйдырганнар. Шулай итеп, бу гаиләнең Россия күләмендәге бүләккә дә лаек икәне ачыклана.

– Биреләсе бүләк безгә тагын да зур җаваплылык өсти. Россия күләмендә гаиләбезне үрнәк итеп күрсәткәннәр икән, инде алга таба да матур итеп яшәргә кирәк. Гаиләмнең бәхете минем кулымда икәнне беләм мин. Әнә шуңа да булдыра алганча тырышырмын, гаилә учагының җылысын картлык көнебезгә кадәр саклый алырмын дип уйлыйм, – ди Чулпан. – Иршатны сайлап, мин бәхетле тормышны сайлаганмын. Балалар алып кайтып, үз оямны тагын да зурайттым. Кадерле әни булып яшим. Тормышыма шөкер итәрлек. Һәр кешегә шуны телим.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КАЗ АСРАУЧЫ РӘХИЛӘ ЗӘЙНУЛЛИНА:

«МАТУРКАЙЛАРЫМ» ДИП ЭНДӘШӘМ»

Балтач

Авыл капкасы

Балтач районының Кариле авылында яшәүче Зәйнуллиннар хуҗалыгында бу көннәрдә каз өмәсе гөрли. Мин шалтыратканда да каз йолкыган мәлләре иде.

– Күп түгел, быел 200 генә каз үстердек, – дип көлә уңган хуҗабикә Рәхилә. – 25 каздан башлаган идек. Аннан илле, йөз, йөз илле иттек. Үткән ел 150 каз җитми калды, шуңа быел тагын арттырырга булдык. Дөрес, аңа кадәр дә казлар үстердек, асрадык. Алары үзебез өчен генә иде. Бер үстерә башлагач, кызыксынып китәсең. Сатып алучылар да: «Казларыгыз бик матур, симез, чиста, ите тәмле», – дип үсендереп тора. Ике ел инде Линда токымлы кара төстәге каз бәбкәләре үстерәбез. Аларын сатып алабыз. Үзебезнең инкубатор да бар. Анда берничә токымлы үзебез асраган каз һәм үрдәкләр салган йомыркалардан бәбкә чыгарабыз.

:: Бу вакытта берьюлы күп итеп эшкәртелгән казларны кайда саклыйсыз?

– Зур туңдыргычыбыз бар. Әмма казларны анда куеп өлгермибез дисәң дә була. Уңайлы булсын өчен, алдан заказ җыябыз. Кешеләр никахка, туйга дип сораганда, берничәшәрне дә эшкәртеп бирәбез. Казларны бик күп сорыйлар, үзебезнең районнан гына түгел, Казаннан, башка районнардан да килеп алалар. Берьюлы бишәр-алтышарны алып китүчеләр бар.

:: Аның кадәр казларның баш-аягы, «дирбия»ләре бар бит әле...

– Аларына казларны эшкәртә башлаганчы заказлар җыйнала. Ирем Фәрит кардада йөргән вакытта ук: «Бу казларның башы юк инде», – дип көлә. Әле бит без чебешләр дә алабыз. Ел саен 100–150ләп, партияләп алып, берничә тапкыр үстереп сатабыз. Быел, мәсәлән, 600 чеби үстердек. 22–25 көнлекне алабыз да, бер ай үстереп, эшкәртеп сатабыз. Аларны да, үрдәкләрне дә бик яратып алалар.

:: Моның кадәр кош-кортны нихәлләр карап, үстереп бетерәсез? Аларга нәрсәләр ашатасыз?

– Без бит әти-әни белән төп йортта яшибез. Алар да, без олы яшьтә инде, дип тик утырмый, бөтен эшебездә булышалар. Үзебез дә авырсынып эшләмибез. Малларны бит яратып карарга, үстерергә генә кирәк, бер авырлыгы да юк. «Китегез моннан, ычкыныгыз әле», – дип каһәрләсәң, бер мал да, кош-корт та үсми. Мин барысына да «матуркайларым» дип кенә эндәшәм. Ә ашатуга килгәндә, без аларга бодай, арпа, борчак, кукуруз... – барысын да пешереп ашатабыз. Әллә нинди өстәмәләр биргәнебез юк. Биш сыерыбыз бар. Аертылган сөт, эремчек кош-корт өчен бик әйбәт. Бәбкә-чебешләр хәзер «күтәрелеп» китә. Бәрәңге дә пешерәбез. Көзгә таба чөгендер, кабак та ашатабыз. Аларын да күп итеп үстерәбез.

:: Казларга, үрдәкләргә сулык та кирәк бит әле.

– Без үстергән токымнарга суда коену, көн-төн суда йөзү кирәк түгел. Бакчабыз инешкә терәлеп кенә тора. Шунда алып төшеп коендырып алып менәбез дә калган вакытны кардада – иркендә торалар.

:: Кара токымлы каз-үрдәк асрап, чистартып караган кеше белә: алардан «товарный вид» ясар өчен шактый тырышырга кирәк. Сезнең казларыгыз ул яктан сынатмый. Түшкә чистартуның берәр җае бармы?

– Каз йолкучы кызларым бик тырыша. Без йонны пешекләп йолкыйбыз. Эчләрен алып, чистартып, юып бетергәч, тоз салып кайнаткан чиста кайнар суга манчып алабыз. Аннан инде тастымал белән корытабыз гына. Казлар матурланып та китә, сөле дә акмый. Кешеләр ышанып сиңа килгәч, алар да канәгать калсын дип тырышабыз. Шулай булмаса, кабат ул сиңа килми инде. Шөкер, даими сатып алучыларыбыз күп.

Автор фотосы

«Каз түшкәләрен күркәм кыяфәткә кертүнең үз җае бар», – ди Рәхилә Зәйнуллина (сулдан беренче).

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Каз итеннән тәмле бәлеш



Камыр әзерләү. Савытка йомырка сыталар да тоз сибеп, сөт өсте, май һәм су салып болгаталар. Шуннан соң камыр басалар.
Эчлек. Бәлешкә дигән каз итен яхшылап юып, 25–30 граммлы кисәкләргә бүлгәләп турыйлар. Итне сөягеннән аерырга кирәкми. Эре итеп тураган бәрәңге, суган өстиләр, тоз һәм борыч сибәләр.
Каз бәлеше 2–2,5 сәгать чамасы пешә.
Бер бәлешкә 1,3 кг төче камыр, 1,5–2 кг каз ите, 1,5–2 кг бәрәңге, 200 г суган, 400–500 г каз шулпасы, тоз, борыч кирәк.

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Байлык

Бер танышымда кунакта булып кайттым да үземнең ни дәрәҗәдә хәерче икәнемне аңлап шаккаттым. Аңа кадәр үземне ничава гына яшим дип уйлый идем. Мин уйлаган нәрсәләрнең күбесе дөрес булып чыга, ләкин монысы алай түгел икән. Ул – бай кеше. Бөтен нәрсәсе дә минекеннән артык. Күпкә артык. Шулкадәр дә бай булып яшәп була микән дип, мин шаккаттым.

Бай дип әйтәм, чөнки ул мөлкәт туплаучы түгел. Ул – чынлап та, бай кеше. Җырлар ярата, үзе дә җырлый. Әдәби китаплар укый, мин яраткан татар язучыларын ярата: Фатих Әмирханны, Әмирхан Еникине, Фатих Хөснине, Флүс Латыйфины, Нияз Акмаловны... Атнабайны... Ркаилне, Газинурны... Ул хәтта мине дә әйбәт язучы дип уйлый. «Тере классик», – дигән була. Болай әйтүләрен мин бик яратып бетермим, тик барыбер «тере мәет» яки «үле классик» дигәнгә караганда яхшырак бит инде. Күпкә. Мин үземне «яшь язучы» диюләрен теләр идем. Тик моның мөмкин түгеллеген аңлыйм: бер үк вакытта яшь тә, язучы да булып булмый. Икенең бере генә: яки син яшь, яки язучы. Яшь язучы ул – яшьлек белән язучылык арасында буталып йөргән кеше.

Менә шул әйбәт язучы дип уйлаганы өчен ул минем белән аралашырга тели, кайбер чыгымнарымны каплый, кунакка чакыра. Бер карасаң, әйбәт инде бу. Икенче карасаң, алай ук түгел. Шулай өлтерәп торган кешене мин үзем дә чакырырга тиешмен бит. Нәрсәм беләндер аптыратырга тиешмен. Ә ул – байлык мәсьәләсендә тере классик, берни белән дә аптырата алмыйсың.

Мин анда кунакта. Ихатасындагы бүлмәне мин хәтта сурәтли дә алмыйм. Әллә ничә почмаклы һәм аның һәр яссылыгында табигать күренешләре төшерелгән. Түшәмендә – йолдызлы күк йөзе. Аннан-моннан гына ясалган сурәтләр түгел бу, ниндидер рәссам бик тырышып, бөтен сәләтен биреп ясаган күренешләр. Карасаң, күзеңне алып булмый. Сокланып туеп булмый.

Мин көнләшеп кайттым. Әйбәт әйбер йогышлы була бит ул. Шушындый ук күренешне үземнең авылдагы йортта ясыйсым килде. Теләк – бер нәрсә, кодрәт – бүтән.

Мин андый нәрсә ясый алмадым. Аны ясарлык акча туплау өчен минем бу илдәге язучылык кына җитми, я базарда ит чабучы булып, я шәп җирдә сатучы булып эшләргә тиеш идем. Булмады. Һәм Ходайның бер хикмәте белән теге кеше үзе миндә кунак булырга теләде.

Ә минем – авыл. Әни йорты. Ул китәр алдыннан: «Балам, монда яшәгез димим инде. Тик өемне ятим калдырмагыз», – дигәнрәк сүз әйткән иде. Мактану кебек ишетелсә дә әйтәм инде: «Улым, кулыңнан килмәгән эш юк, эшлә – өем горурланып торырлык булсын», – дигән иде. Мин ризалашкан идем. Ул бит – әтиле малайларның да мунчасы булмаган вакытларда мунча салдырган әни. Ул бит – ирләр белән ярышып дөнья көткән ялгыз хатын. Аның кулыннан килмәгән бернәрсә дә юк һәм минеке дә булырга тиеш түгел иде. Ә чынында... Әле дә рәткә кертеп җиткерелмәгән дөнья. Сүтү белән төзү арасында ул.

Ә кунак килде. Ашау-эчүгә кытлык түгел хәзер. Аллага шөкер итеп кенә яшәрлек. Матур итеп утырдык. Сөн буена барып килдек. Урманнарда йөрдек. Тауларга мендек. Далаларда адаштык... Безнең як табигате бай бит ул, монда кошларның да, җәнлек-җанварның да әллә нинди төрләре бар. Мин аучы түгел, аларны аулау кирәкми, күреп калу да җитә. Үз күзләрең белән төлке яки бүре күрү дә байлыкның бер төре кебек бит инде. Вәт менә без шундый байлыкларның әллә ничә төрен күрдек.

Урап кайткач, ихатада утырдык. Мин акланган булам:

– Миндә шартлар ул кадәр үк түгел инде...

Ә теге һушы китеп утыра икән:

– Марат, син иҗатчы булмый кем булсын инде, – дигән була. – Синең бит стеналарың офыкларга кадәр. Җирең натуральный. Хәтта күкләреңдә дә чын йолдызлар яна... Син бәхетле...

Хак инде ул, бер карасаң. Бәхетле булу өчен миңа бүлмәләр кирәкми. Миңа киңлекләр, биеклекләр, тирәнлекләр кирәк. Әйе, мин кайвакыт һавага карап ятам, офыкка тоташкан киңлекләремә, болытларга ук җитмәгән үз биеклегем кебек тауларыма. Мин бит кайсы илдә, нинди кысада булсам да, шулар арасында яшим. Мин үземне биеклекнең дә, тирәнлекнең дә, киңлекнең дә бер тамчысы итеп тоям. Ә тамчыда бөтен дөнья чагыла. Чагылышын сез дә тоясыздыр...

Юатыр өчен генә әйткәндер дип уйлаган идем. Ә теге үзенә кайткан да теге бүлмәне сүтеп ташлаган. «Синдәге кебек хөррият тудырасым килде», – ди. Тирә-ягыма карыйм, бер рәссамның картинасы кирәкми – барысы да табигый. Җиргә карыйм – үләннәрне тыңлап була. Күкләргә карыйм...

Ә мин аның сүтеп ташлавын өнәмәдем. Торсын иде аның теге бүлмәсе. Матур иде ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

И туган тел, и матур тел...

Үз илемдә – үз телем

«Ватаным Татарстан» газетасының махсус проекты Татарстандагы төрле милләтләрнең яшәеше, гореф-гадәтләре белән таныштыра, «Бер гаилә мисалында туган телне ничек сакларга?» дигән сорауга җавап эзли.

ҮЗБӘК

Питрәч

СЫЕНУ

Питрәч районының Колай авылында яшәүче Дощановлар гаиләсенә баргач, гадәт буенча рус телендә сөйләшә башлаган идек. Үзбәк милләтеннән алар. Тик үзебез дә сизмәстән татарчага күчкәнбез икән. Йорт хуҗалары аратирә үзбәкчә дә сүз алышалар. Бигрәк тә аш-су тирәсендә. Милли ризыклар әзерләп, кунакларны гаҗәпләндермәкчеләр бугай.

Эшләп кеше үлми

Монда һәркемнең – үз эше. Йорт хуҗасы Сапарбой оныгы Ясминәне кулыннан төшерми. Уллары Сардар ерак рейсларга йөри икән: Пермьгә китәргә җыена. Киленнәре Дилфүзә белән кызлары Гүзәл аш-су тирәсендә кайнаша. Мәктәптә укучы оныклары Сәед белән Сәмир уку әсбаплары янында мәш килә. Тәмле исләр бик борынны кытыкламый торсын дип, хуҗабикә Рано белән без дә балалар бүлмәсенә елыштык.

– Ике ел чамасы яшәп карыйк та, барып чыкмаса, кайтып китәрбез, дип төпләнгән идек Колай авылына. Бөтенләйгә булган икән. 1 сентябрьдә килгәнебезгә 25 ел булды. Кире китү турында уйлаганыбыз да юк.Ияләштек, – дип башлады ул сүзен. – Ул вакытта совхоз иде әле. Эш урынында да, яшәгән җирдә дә бик якын күрделәр, үз иттеләр. Бер якта – таҗиклар, икенчесендә руслар яши. Дус, тату гомер кичерәбез, кунакка йөрешәбез. Мәктәптә дә бернинди проблемалар булмады. Өч балам бик яхшы укыды. Гүзәл «5»кә генә бетерде. Быел Казан сәүдә-икътисад техникумын тәмамлап, эшкә урнашты. Хәзер оныклар шул ук мәктәпкә йөри.

Татарстанга килгәнебезгә бер дә үкенмибез. Яшермим, башта авыррак булды. Шул вакытларда, әти безне дөрес тәрбияләгән икән, дигән фикергә килдем. Әнием Җомагөл бакыйлыкка күчкәндә, миңа 2 генә яшь булган. Безне Зариф әтиебез үстерде. Унөч ел элек вафат булды. Эшләп кеше үлми, дия-дия, эшләтеп үстергән иде ул безне. Колайга килеп урнашкач, өч сыер асрадык. Күршедәге хатыннар каймак-катык кебек ризыклар әзерләргә өйрәтте. Үзебез дә ач булмадык, сатарга да калды. Бер минут та тик торганыбыз юк.

Хуҗалыклары белән танышкач, бу сүзләрнең чыннан да дөреслегенә ышанасың. 33 сутый җирдә яшелчә, җиләк-җимеш үстергәннәр, кышка әзерләгәннәр. Сапарбой совхозда механизатор булып эшләгән. Алтын куллы булуы белән дан тоткан, теләсә нинди техниканы төзәтә алган. Китмәсен дип, аңа совхоз йорт та салып биргән. Кайчандыр совхоз К-700 тракторын металлоломга чыгарып аткан булган. Аны да төзәтеп иярләгән. Ишегалдында берничә машинасы бар: ниндие кирәк, шуңа утырып чыгып китә икән. Хәзер дә Колайдагы «Автодор» оешмасында тракторчы булып эшли. Рано – психиатрия хастаханәсендә санитарка. Аңа кадәр Колайдагы фермада сыер сауган. Дилфүзә дә фермада эшләгән җиреннән декрет ялына чыккан. «Хәләл эшләп алган акчаның ояты юк, – диләр алар. – Үзбәкстанда да гел эшләдек. Йөз гектар җиребез бар иде. Гаилә ишле булды. Бер ир бала, дүрт кыз үстек. Кукуруз, кавын, карбыз, дөге үстердек. Тик аны урнаштыру гына бик авыр булды».

Әтием киңәшләре

- Буш урын күрдеңме, әйбер утыртып куй, үссен. Үзең ашамасаң, күршең ашар.
- Дошманың таш белән орса да, син аш белән борыл, аннары дуслашып китәрсез.
- Хайван асраудан курыкма, ризыгың булыр.

Чит кешеләр түгел

Дощановлар Татарстанда чит кешеләр түгел. Сапарбойның әнисе Сания Сәйфуллина Питрәч районындагы Күн авылында туып-үскән. Пермьдә шахтада эшләгәндә, Таир исемле үзбәк егете белән өйләнешкәннәр дә аның туган ягына юл тотканнар. Татарстанга еш кайтып йөргәннәр. Сапарбой хәтта Күн авылында туган да.

– Каенанам 9 бала тапкан, – дип дәвам итте сүзен Рано. – Без дә, өйләнешкәч, Татарстанга кайтып йөрдек әле. СССР таркалгач кына проблема башланды. Сапарбойның туганнары да бар Казанда. Аралашып торабыз. Бигрәк тә дини бәйрәмнәрдә очрашабыз. Үземнең дә бер энекәшем Казанда яши.

Мөмкинлек бар әле

– Колай рус авылы булгач, күбрәк шул телдә сөйләшергә туры килә инде. Әмма, ничектер, без бик тиз татар сөйләменә авыштык. Әтиебез заманында: «Без – каракалпак үзбәкләре, – дип сөйли иде. – Ничәнче елларда икәнен төгәл хәтерләмим. Каракалпаклар арасында чуалышлар башлангач, алар гаилә белән Үзбәкстанның Беруни шәһәренә качып килгәннәр. Анда үзбәк дип язылганнар. Ә каракалпак теле татар теленә бик охшаш. Безгә шуңа күрә якындыр ул дип уйлыйм. Татарча рәхәтләнеп сөйләшәбез. Безнең оныклар татар телен хәтта Колай мәктәбендәге укучыларга караганда да яхшы белә. Форсаттан файдаланып, шуны да әйтәсе килә: татар телен күбрәк укытсыннар иде мәктәпләрдә. Шул ук вакытта үз телебезне дә онытмыйбыз. Гаиләдә үзбәкчә генә сөйләшәбез. Башка милләттәшләребез белән дә аралашабыз. Телне, гореф-гадәтләрне саклау турында фикер алышабыз. Аңлыйбыз инде, әлбәттә, чит җирләрдә булгач, телне белү кайчандыр өзелергә дә мөмкин. Безнең белән үзбәкчә сөйләшсәләр дә, Сәед белән Сәмир үзара русча сөйләшергә генә торалар. Әмма әлегә телебезне сакларга мөмкинлегебез бар, Аллага шөкер.

Мәскәүдә яшәүче улым Салаватның хәләл җефете – удмурт милләтеннән, Ольга исемле. Ике якның әти-әниләре дә балаларыбыз теләгенә каршы килмәдек. Киленебезнең ризалыгын алып, никах укыттык. Әле ул яныма: «Әнәй, исемемне дә алыштырырга кирәкме?» – дип килгән иде. «Ник, ошатмыйсыңмыни? Бик матур бит», – дигәч, елмаеп куйды. Үзбәкчә аңлый. Кай арада өйрәнеп өлгергәндер, белмим. Оныгыбыз Эмилия тугач, ислам йоласы буенча исем куштырдык. Ике якның да тамырларын белеп үссеннәр дип телибез.

Сардар Дилфүзә белән интернет аша танышты. Үзбәкстанга барып, гореф-гадәткә туры китереп, туй ясап алып кайттык. Баштарак читенсенде кебек. Елап та ала иде. Хәзер ияләште инде. Күп итеп балалар тап, курыкма, үзем булышырмын, дип әйтәм. Үзем өч баламны югалттым. Бик авыр хәсрәт ул. Үзбәкстаннан китүебезнең дә төп сәбәбе шунда иде. Сырдәрья суы ел саен ярларыннан ташып чыгу сәбәпле, бик каты авыру таралды. Балаларыбызны дәвалый, саклап кала алмадык. Форсаттан файдаланып, Татарстан Хөкүмәтенә зур рәхмәтләребезне җиткерәбез. Безне сыендырды, эшле-ашлы итте. Киләчәктә дә дус-тату яшәргә язсын иде.

Табын күрке – пылау

✓ Дөгене су үтә күренмәле булганчы юарга. Сарымсакны кабыгыннан чистартырга, әмма тырнакларга бүлмәскә. Өчәр баш суган һәм кишерне чистартырга. Суганны – ярымбоҗра, кишерне салам рәвешендә турарга.

✓ Казанны җылытырга һәм май кыздырырга. Шушы майда чистартылмаган суганны кап-кара булганчы кыздырырга. Алып ташларга. Калган туралган суганны, болгата-болгата, куе алтын төскә кергәнче кыздырырга. Бу 10 минуттан азрак вакытны алачак. Шакмаклап туралган ит өстәргә, тышча барлыкка килгәнче кыздырырга.

✓ Кишер өстәргә. Болгатмыйча гына – 3 минут, аннары, болгата-болгата, тагын 10 минут кыздырырга. Казанга салынган әйберләрдән бер сантиметр артып торырлык итеп, кайнап торган су агызырга. Кипкән әче борыч өстәргә. Бер сәгать акрын утта тотарга.

✓ Дөгене тагын бер кат юарга, суын агызып бетерергә. Ит өстенә тигезләп салырга. Утны арттырырга һәм казанга дөге катламыннан өч см чыгып торырлык итеп, кайнап торган су өстәргә.

✓ Дөге суны үзенә сеңдерү белән казанга сарымсак салырга һәм утны уртачага куеп, дөге әзер булганчы тотарга. Агач таякчык белән берничә урыннан тишәргә. Дөге әзер булгач, казанны капларга, иң кечкенә утка куярга һәм 30 минут тотарга.

Үзбәк йортында көндәлек кагыйдәләр

- Өлкән кешене, динне хөрмәт итегез.
- Өстәл түрендә ата кеше утырырга тиеш.
- Чит кешеләрнең кирәкмәгән сүзләренә бирешмәгез.
- Мәчеткә баргач, читтә генә утырыгыз, өлкәннәргә комачауламагыз. Сәдакагызны бирегез дә тыныч кына кайтып китегез.

Сәхифәне Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде. Фото – Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 333

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+